2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авылы җирлеге Каськи авылы гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

9 декабрь 2023 ел №8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Каськи авылында гражданнар җыены:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Каськи авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 7500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пункт территориясен төзекләндерү (эскәмияләр, өстәлләр, биотуалетлар, вак ташлар сатып алу)?».

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорт, Каськи авылы, Полевая урамы, 15а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин